| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>АГРЫЗСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2025 г. Агрыз № 4-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2025 елның 24 июнендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында "гы 47-4 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Гавәми хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" гы 2025 елның 20 мартында кабул ителгән 33-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында"гы 2007 елның 02 мартында кабул ителгән 25-ФЗ номерлы Федераль закон, "Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексын раслау турында"гы 2013 елның 25 июнендә кабул ителгән 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында»гы 2025 елның 24 июнендә кабул ителгән 47-4нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 8нче бүлегендәге 3нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәт вазифаларын биләү өчен түбәндәге гомуми квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу - вазифаларның югары, төп һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен (авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазифалардан тыш); югары белем яисә урта һөнәри белем булу - авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазифаларның югары, төп һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазифаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек буенча эш стажына: әзерлек юнәлеше буенча:

муниципаль хезмәтнең югары вазифалары буенча - муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек буенча стаж кимендә бер ел, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазифалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек буенча, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru)

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 13 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л. Ф. Нургаянов